
# Яшелчәләр













**Бармак уены «Яшелчәләр»**

**1 .Рәсемдә нәрсәләр ясалган? Исемнәрен ата.**

**2.Бармак уенын кабатла.**

**3. Шигырьнең эчтәлегенә туры китереп бармакларны бөкләп бар.**

**<u>Үрнәк: </u>Бу бармак- кыяр. Бу бармак -кәбестә. Бу бармак- кишер. Бу бармак –помидор. Бусы сарымсак булды.Менә кәрзинем тулды..**



# Уенчыклар











Бармак уены «Уенчыклар»

Бабай  алды барабан,
Әби алды бөтерчек,
Әти алды машина,
Әни алды сикергеч,
Ә мин алам  да зур туп,
Уйныйм тупны сикертеп.

# Кошлар













Бу бармак –чыпчык,
Бусы-сыерчык,
Бусы-карлыгач,
Бусы –сандугач.

Ә бусы бик кечкенә,
Тимәгез нәниемә,
Нәнием –чәнтиемә.

# Кыргый хайваннар














Баш бармагым бүредер,
Имән бармагым-төлке,
Урта бармагым-бурсык,

Атсыз бармагым- аю,
Чәнти бармагым –куян,
Куянны кая куям?

# Җиләк-җимешләр













Баш бармак- балан,
Имән бармак-карлыган,
Урта бармак-бөрлегән,

Атсыз бармак –алма,
Чәнти бармагым-чия.
Кем күбрәк җимеш җыя?

# Өс киемнәре











Баш бармак башлык кигән,
Имән бармак итәк кигән,
Урта бармак зур тун кигән,

Атсыз бармак чалбар кигән,
Чәнти бармагым киенмәгән.
Әллә киенә белмәгән?

# Аяк киемнәре













Баш бармак башмак кигән,
Имән бармак итектән,
Урта бармак унты тапкан,

Атсыз бармак сандалидан,
Ә чәнтием читектән чиккән.
Читек киеп биеп киткән!

# Савыт-саба














Баш бармак чынаяк ала,
Имән бармак - тәлинкә,
Урта бармак -чәнечке,

Атсыз бармак аш сала,
Чәнти бармагы ала кашык .
Утырырга,әйдә,ашык!